РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Малосалтыковского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кече Салтык**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Б. Урманче, 9 с. Малые Салтыки, 422812
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 9405059 ОГРН 1061672018033
ИНН/КПП 1622004757/1162201001

Б.Урманче урамы, 9,Кече Салтык авылы, 422812,
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 9405059 ОГРН 1061672018033
ИНН/КПП 1622004757/1162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«29» январь 2021ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегендә 2021 елда җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары» нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегендә № 1 кушымта һәм № 2 кушымта нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә, күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 30.01.2020 ел, № 3 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
- Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9 йорт;
- Кече Мәрәтхуҗа авылы, Гагарин урамы, авыл клубы бинасы, шулай ук хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен бирә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Г.Җиһаншин**

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына кушымта
№ 1 «29» гыйнвар 2021 ел

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән алып җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен табут һәм башка кирәк булган предметларны китереп бирү | 3850,02 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) китерү | 547,86 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| **Барысы** | **6424,98** |

Кушымта № 2
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына кушымта
№ 1 «29» гыйнвар 2021 ел

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән алып җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенлек | 197,58 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3652,44 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 547,86 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| **Барысы** | **6424,98** |